**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 ноябрь № 889

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче; 2015 ел, 20 февраль, 104 нче; 2015 ел, 10 март, 140 нчы; 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы; 2015 ел, 16 май, 350 нче; 2015 ел, 14 август, 591 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Мәгариф хезмәткәрләре эш хакының база ставкасы өчен (база оклады) сәгатьләр саны

4.1. Эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Педагогика хезмәткәрләренең эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) турында һәм хезмәт шартнамәсендә килешенгән педагогика хезмәткәрләренең укыту йөкләмәсен билгеләү тәртибе хакында» 2014 ел, 22 декабрь, 1601 нче боерыгы белән билгеләнгән.

Педагогика хезмәткәрләре өчен эш вакыты дәвамлылыгы (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы) атнасына 36 сәгатьтән артык булмаган кыскартылган эш вакыты дәвамлылыгыннан чыгып билгеләнә.

4.2. Вазыйфасына һәм (яки) белгечлегенә бәйле педагогика хезмәткәрләренә түбәндәге эш вакыты дәвамлылыгы яки эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы билгеләнә.

4.2.1. Атнасына 36 сәгатьтән артык булмаган кыскартылган эш вакыты дәвамлылыгы түбәндәгеләргә билгеләнә:

мәктәпкәчә белемнең белем бирү программалары һәм өстәмә гомуми белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның һәм өстәмә төр эшчәнлек сыйфатында бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган балалар йортларының өлкән тәрбиячеләренә;

педагог-психологларга;

социаль педагогларга;

педагог-оештыручыларга;

җитештерүдәге укыту осталарына;

өлкән әйдаманнарга;

хезмәт инструкторларына;

педагог-китапханәчеләргә;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар методистларына һәм өлкән методистларына;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның тьюторларына, югары белемнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган оешмалардан тыш;

урта һөнәри белемнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның физик тәрбия җитәкчеләренә;

тормыш иминлеге нигезләрен укытучы-оештыручыларга;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның инструктор-методистларына, өлкән инструктор-методистларына.

4.2.2. Атнасына 30 сәгать эш вакыты дәвамлылыгы өлкән тәрбиячеләргә билгеләнә (әлеге пунктның 4.2.1 пунктчасында күрсәтелгән өлкән тәрбиячеләрдән тыш).

4.2.3. Эш хакы ставкасы өчен атнасына 20 сәгать педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

укытучы-дефектологларга;

укытучы-логопедларга.

4.2.4. Эш хакы ставкасы өчен атнасына 24 сәгать педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

музыкаль җитәкчеләргә;

концертмейстерларга.

4.2.5. Эш хакы ставкасы өчен атнасына 25 сәгать педагогик эш сәгатьләре нормасы сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны (тәрбияләнүчеләрне) укытуны, тәрбияләүне, карауны турыдан-туры гамәлгә ашыручы тәрбиячеләргә билгеләнә.

4.2.6. Эш хакы ставкасы өчен атнасына 30 сәгать педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

физик культура инструкторларына;

төп гомуми белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган, тәрбияләнүчеләрнең интернатта яшәве өчен, шулай ук озайтылган көн төркемнәрендә балаларны карауны һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырылган оешмалар; ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар; туберкулез авырулы укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен, шул исәптән шифаханә, оешмалары (төркемнәре); медицина оешмалары; эшчәнлекнең өстәмә төре сыйфатында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (алга таба - медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) тәрбиячеләренә (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы әлеге пунктның 4.2.5 һәм 4.2.7 пунктчаларында күздә тотылган тәрбиячеләрдән тыш);

туберкулез авырулы укучылар (тәрбияләнүчеләр) өчен, шул исәптән шифаханә, оешмаларының (төркемнәренең) кече тәрбиячеләргә һәм тәрбияче ярдәмчеләренә.

4.2.7. Эш хакы ставкасы өчен атнасына 36 сәгать педагогик эш сәгатьләре нормасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

өстәмә гомуми белем бирү программалары, мәктәпкәчә белемнең белем бирү программалары, урта һөнәри белемнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган, шулай ук балаларны карауны һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыручы тәрбиячеләргә (эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы әлеге пунктның 4.2.5 һәм 4.2.6 пунктчаларында күздә тотылган тәрбиячеләрдән тыш);

сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән тәрбияләнүчеләр өчен оешмаларның (төркемнәрнең) кече тәрбиячеләренә һәм тәрбияче ярдәмчеләренә.

4.2.8. Әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән педагогика хезмәткәрләренә эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормасы булып аларның педагогик эшчәнлегенең нормалаштырыла торган өлешен булган уку (укыту) эше сәгатьләре нормасы тора (алга таба - уку (укыту) эше сәгатьләре нормасы).

а) эш хакы ставкасы өчен атнасына 18 сәгать уку (укыту) эше сәгатьләре нормасы түбәндәгеләргә билгеләнә:

төп гомуми белем программалары (шул исәптән җайлаштырылган) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар укытучыларына;

сәнгать, физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә гомуми белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар укытучыларына;

өстәмә белем бирүче укытучыларга һәм өстәмә белем бирүче өлкән укытучыларга;

физик культура һәм спорт өлкәсендә белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның тренер-укытучыларына һәм өлкән тренер-укытучыларына;

медицина оешмаларының һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының логопедларына;

мәктәпкәчә белем оешмаларының чит тел укытучыларына;

педагогика юнәлешендәге урта һөнәри белем программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар укытучыларына (күрсәтелгән оешмаларның эш хакы ставкасы өчен елына 720 сәгать уку (укыту) эше сәгатьләре нормасын куллануучы укытучыларыннан тыш).

б) эш хакы ставкасы өчен елына 720 сәгать уку (укыту) эше сәгатьләре нормасы урта һөнәри белем программалары, шул исәптән сәнгать өлкәсендә интегрирлашкан белем программалары буенча (әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән укытучылардан тыш) һәм һөнәри укытуның төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар укытучыларына.

Биләгән вазыйфасына бәйле педагогика хезмәткәрләренең эш сәгатенә уку (укыту) эше, тәрбия эше, укучылар белән шәхси эш, фәнни, иҗади һәм тикшеренү эше, шулай ук хезмәт (вазыйфаи) бурычлар һәм (яки) шәхси планда каралган башка педагогик эш – методик, әзерлек, оештыру, диагностик эш, мониторинг алып бару буенча эш, тәрбия, физкультура-сәламәтләндерү, спорт, иҗади һәм укучылар белән үткәрелә торган бүтән чаралар планнарында каралган эш кертелә.

Әлеге пунктның 4.2.5 һәм 4.2.6 пунктчаларында күздә тотылган педагогика хезмәткәрләренең эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары астрономик сәгатьләрдә билгеләнә. Әлеге пунктның 4.2.8 пунктчасында күздә тотылган уку (укыту) эше сәгатьләре нормалары астрономик сәгатьләрдә билгеләнә, кыска туктап торуларны (тәнәфесләрне), динамик паузаны үз эченә ала.

Әлеге пунктның 4.2.5 – 4.2.7 пунктчаларында күздә тотылган эш хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары һәм әлеге пунктның 4.2.8 пунктчасында күздә тотылган уку (укыту) эше сәгатьләре нормалары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма билгеләгән атнасына (елына) педагогик эш яки уку (укыту) эше күләмен исәпкә алып, педагогика хезмәткәрләренә бер айга эш хакын исәпләү өчен исәп-хисап зурлыклары булып тора.

Педагогика хезмәткәренең язмача ризалыгы белән эш хакы ставкасы өчен билгеләнгән эш сәгатьләре нормаларыннан артыграк яисә эш хакы ставкасы өчен билгеләнгән эш сәгатьләре нормаларыннан кимрәк башкарылган педагогик эш яки уку (укыту) эше өчен түләү эш хакы ставкасының билгеләнгән күләменнән чыгып

гамәлдә билгеләнгән педагогик эшкә яки уку (укыту) эшенә пропорциональ рәвештә башкарыла, атнасына эш хакы ставкасы өчен билгеләнгән уку (укыту) эше сәгатьләре нормасына туры килгән күләмдә уку йөкләнеше тәэмин ителә алмаган укытучыларга тулы күләмдә эш хакы ставкаларын түләү очракларыннан тыш.»;

8 бүлекнең 5 таблицасында:

23 һәм 24 юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «23. | Гомуми белем бирү оешмаларында («башлангыч мәктәп-балалар бакчасы», «кече гимназия» статусына ия булганнарыннан тыш) һәм мәктәпара укыту комбинатларында эш | башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыручы педагогика хезмәткәрләре вазыйфасы | 1 – 4 | 45,0 |
| | | мәктәпкәчә белемнең белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген тормышка ашыручы педагогика хезмәткәрләре вазыйфасы | 1 – 4 | 37,0 |
| 24. | Мәктәпкәчә белемнең белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген тормышка ашырган һәм «башлангыч мәктәп-балалар бакчасы», «кече гимназия» статусына ия булган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм гомуми белем бирү оешмаларында эш | педагогика хезмәткәрләре эшчәнлеге | 1 – 4 | 45,0 |
| | | беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | 1 | 10,0 |
| | | икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал вазыйфалары | 1 – 2 | 10,0»; |

25 юлның 2 графасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмаларында һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруга булышлык итү, алмаштыручы гаиләләрне әзерләү һәм ярдәм күрсәтү үзәкләрендә эш»;

9 бүлекнең 13 таблицасындагы 4 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен белем бирү оешмалары; сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, тәрбияләнүчеләр өчен белем бирү оешмалары; озак вакыт дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә белем бирү оешмалары; девиант тәртипле укучылар өчен махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләре; интернаты булган гомуми белем бирү оешмалары (шул исәптән кадетларныкы, лицей-интернатлар, гимназия-интернатлар)».

2. Бу карарның көчен 2015 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\889.docx